| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**14.10.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2833** |

Гавами сервитут
билгеләү турында

«Спектр» ҖЧҖ (ОГРН 1037821020951, ИНН 7810215631) үтенечнамәсен карап, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлегенә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясына, 2001 елның 25 октябрендәге «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3.6 статьясына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Җир кишәрлекләре өлешендә су бүлеп бирү системасының линияле объектларыннан файдалану өчен 49 елга гавами сервитут билгеләү турында «СПЕКТР» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять үтенечнамәсе нигезендә түбәндәге гавами сервитут билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Осиново авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:20:080802:653 кадастр номерлы, 1281 кв. м. мәйданлы җир кишәрлегендә,

2) Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Осиново авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:20:080802:242 кадастр номерлы, 188 кв. м. мәйданлы җир кишәрлегендә,

3) Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Осиново авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:20:000000:5264 кадастр номерлы, 1425 кв. м. мәйданлы җир кишәрлегендә,

2. Су бүлеп бирү системасының линия объектларын эксплуатацияләү максатларында гавами сервитут чикләре урынының кушымтада бирелгән график тасвирламасын расларга (1 нче кушымта).

3. «Спектр» (ОГРН 1037821020951, ИНН 7810215631) җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен гавами сервитутның иясе итеп билгеләргә.

4. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гавами сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясы нигезендә билгеләнә;

җир кишәрлегеннән (аның өлешеннән) һәм (яисә) анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектыннан, алардан рөхсәт ителгән файдалану нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.41 ст. 1 п.4 п. п. нигезендә гамәви сервитут билгеләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә файдалану мөмкин булмаган яисә сизелерлек кыенлашкан срогы юк.

5. «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте идарәсенә, гавами сервитут билгеләү турында карар кабул ителгән җир кишәрлекләренең хокук ияләренә җибәрүне;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына гавами сервитут билгеләү турында белешмәләр кертүне;

гавами сервитут хуҗасына гавами сервитут билгеләү турында карар күчермәсен, җир кишәрлегенең хокук иясе булган зат турында белешмәләрне, җир кишәрлекләренә хокукларын исәпкә алу турында гариза биргән затлар турында белешмәләрне, алар белән элемтә ысулларын, күрсәтелгән затларның җир кишәрлекләренә хокукын раслый торган документларның күчермәләрен җибәрергә.

6. «Спектр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә:

җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән гавами сервитут билгеләү турында килешү төзергә;

вәкаләтле органга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 20 декабрендәге 878 номерлы карары нигезендә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектка карата саклау зонасы чикләрен раслау турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә;

төзелеш-монтаж эшләрен башкару графигы буенча җир кишәрлекләрендә төзелеш-монтаж эшләрен һәм планлы (ремонт) ремонт эшләрен елга бер тапкыр башкарырга.

7. «Спектр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалану төренә туры китереп файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә, гавами сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын, тәэмин итү өчен гавами сервитут урнаштырылган эшчәнлек тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.50 статьясында билгеләнгән срокларда сүтергә.


8. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Схема размещения объекта на земельном участке
с кадастровым номером16:20:080802:653

Система к




| | |
|---|---|
| н1 | 487310.27 |
| н2 | 487308.09 |
| н3 | 487301.46 |
| н4 | 487288.73 |
| н5 | 487194.10 |
| н6 | 487136.14 |
| н7 | 487086.05 |
| н8 | 487085.14 |
| н9 | 487083.59 |
| н10 | 487078.99 |
| н11 | 487062.79 |
| н12 | 487047.57 |
| н13 | 487039.38 |
| н14 | 487033.35 |
| н15 | 487029.83 |
| н16 | 487026.29 |
| н17 | 487022.65 |
| н18 | 487015.11 |
| н19 | 487010.98 |
| н20 | 487003.64 |
| н21 | 486996.63 |
| н22 | 486990.22 |
| н23 | 486985.95 |
| н24 | 486964.60 |

координаты к
обороте

Условные обозначения:


Часть ЗУ где планируется установить публичный сервитут

Граница участков по ЕГРН

Существующий объект(трубопровод ливневой канализации)

Согласовано:

> и





Система координат: МСК-16

| X | Y |
|---|---|
| 487337,97 | 1295042,30 |
| 487338.75 | 1295046,39 |
| 487338,36 | 1295047.57 |
| 487332,24 | 1295067,05 |
| 487320.03 | 1295104.99 |
| 487311.27 | 1295130.50 |
| 487310.27 | 1295133.66 |
| 487308.09 | 1295133.94 |
| 487309.37 | 1295129.88 |
| 487318.14 | 1295104.36 |
| 487330.33 | 1295066.45 |
| 487336.46 | 1295046.96 |

**Схема размецения оьъекта на земель участке**

16:20:000000:5264 -




Условные обозначения:

|\/ • ■ j Часть ЗУ где планируется сервитут /

Граница участков по ЕГР.Й/ ˣ

Система координат: МСК-16